Татарстан Республикасы Спас муниципаль районы
Өчкүл авыл җирлегенең башкарма комитеты

КАРАР

14.01.2020 №102

Татарстан Республикасы Спас муниципаль районы Өчкүл авыл җирлеге башкарма комитеты муниципаль хезмәткәрләренең Татарстан Республикасы Спас муниципаль районы Өчкүл авыл җирлеге Советы тарафыннан 2013 елның 13 ноябрендә кабул ителгән 53-2 номерлы «Татарстан Республикасы Спас муниципаль районы Өчкүл авыл җирлеге башкарма комитеты муниципаль хезмәткәрләренең җаваплылыгы турындагы нигезләмәне раслау хакында " гы карарына үзгәрешләр кертү турында»

«Коррупциягә каршы тору турында Россия Федерациясе законнарын камилләштерү максатларында Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү хакында» 2019 елның 16 декабрендәге 432-ФЗ номерлы Федераль законның 7 статьясындагы 2 пункты нигезендә, Татарстан Республикасы Спас муниципаль районының Өчкүл авыл җирлеге Советы

КАРАР ИТТЕ:

1. «Татарстан Республикасы Спас муниципаль районының Өчкүл авыл җирлеге башкарма комитетының муниципаль хезмәткәрләренең җаваплылыгы турында» 2013 елның 13 ноябрендәге 53-2 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Спас муниципаль районының Өчкүл авыл җирлеге башкарма комитетының муниципаль хезмәткәрләренең җаваплылыгы хакындагы нигезләмәне раслау хакында» нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. Нигезләмәнең 1 пунктындагы 1.3 пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1.3. Дисциплинар түләтүләрне куллану һәм бетерү тәртибе, әлеге Нигезләмәдә каралган очраклардан тыш, хезмәт законнары белән билгеләнә.».

2. Әлеге карарны Өчкүл авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында, Спас муниципаль районының рәсми сайтында (http:/ www.spasskiy.tatarstan.ru), һәм хокукый мәгълүмат сайтында (http:pravo.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга.

Өчкүл авыл җирлеге башлыгы Н.В. Емелюшина

СОВЕТ ТРЕХОЗЕРСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ